КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 14 август г.Казань № 976

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 19 май, 608 нче карары белән расланган Оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнар өлешен каплау максатларында биналар һәм бүлмәләрне төзү һәм төзекләндерү буенча инвестиция проектын гамәлгә ашыру кысаларында төзелгән күчемсез мөлкәт объектларын арендага бирүче юридик затларга 2023 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнар өлешен каплау максатларында биналар һәм бүлмәләрне төзү һәм төзекләндерү буенча инвестиция проектын гамәлгә ашыру кысаларында төзелгән күчемсез мөлкәт объектларын арендага бирүче юридик затларга 2023 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2023 ел, 19 май, 608 нче белән расланган Оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнар өлешен каплау максатларында биналар һәм бүлмәләрне төзү һәм төзекләндерү буенча инвестиция проектын гамәлгә ашыру кысаларында төзелгән күчемсез мөлкәт объектларын арендага бирүче юридик затларга 2023 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «, саклауның махсус шартларын таләп итмәгән,» сүзләрен төшереп калдырырга.

3 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлык – юридик затларга кунакханә хезмәтләре күрсәтү яисә халык куллану товарларын һәм азык-төлек товарларын саклау буенча хезмәт күрсәтүләр

һәм биналар һәм бүлмәләр төзү һәм реконструкцияләү буенча инвестицион проектны гамәлгә ашыру кысаларында төзелгән ахыргы кулланучыга җибәрүгә аларны комплектацияләү хезмәтләре күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү механизмын гамәлгә ашыру өчен җаваплы республика башкарма хакимият органы;»;

дүртенче абзацта «, саклауның махсус шартларын таләп итмәгән,» сүзләрен төшереп калдырырга.

5 пунктта:

өченче абзацта «сум» сүзеннән соң «өстәлгән бәягә салымны исәпкә алып» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацта «, саклауның махсус шартларын таләп итмәгән,» сүзләрен төшереп калдырырга.

7 пунктның бишенче абзацында «, саклауның махсус шартларын таләп итмәгән,» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин